**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **13.11.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
Районы Мәлбагыш авыл җирлеге составына керүче
Мәлбагыш авылында 2020 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Мәлбагыш авылының Комсомол урамында юлларга таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш төяү)
- Мәлбагыш авылында юлларны кардан чистарту;
- Мәлбагыш кый авылында җәйге вакытта үлән чаптыру, территорияне җыештыру хезмәтләре;
- бүләк, сувенир продукциясе сатып алу, «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Халыкара инвалидлар көне», «Яңа ел», «Җиңү Көне " бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү;»

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мәлбагыш авыл җирлеге Башлыгы И.Ә.Әхтәмова